| | |
|---|---|
| **ГЛАВА СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

с.Старое Шаймурзино

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 18 ноябре № 21

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Шәйморза
авыл җирлегенең Чуваш Шәйморза торак
пунктында үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән расланган Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 07.10.2019 ел, № 51/1 карары (15.11.2019 ел, №53/5 редакциясендә) КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Иске Шәйморза торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабренә 10:30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Чуваш Шәйморза авылы, Татарстаннын 15 ел урамы, 40 йорт, Чуваш Шәйморзасы авылы мәдәният йорты.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Чуваш Шәйморзасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме?:

- Чуваш Шәймoрзасы авылынын Калинин, Чкалов, Пушкин урамындагы юлларга таш салу;
- Чуваш Шәйморзасы авылынын зиратынын коймасын тотарга

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова